СОВЕТ БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.09.2019 ел Олы Подберезье авылы № 15

**Олы Подберезье авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче Федераль законның 56 нчы маддәсе, «Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашу хокукы турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67 нче Федераль законның 15 нче маддәсе, Татарстан Республикасының «Җирле референдум турында»гы 2004 елның елның 25 мартындагы 23 нче законынның 12 нче маддәсе, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставының 11 нче маддәсе нигезендә Олы Подберезье авыл җирлеге Советы **КАРАР** кабул итте:

1. Олы Подберезье авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Олы Подберезье авыл җирлегендә референдум үткәрү турындагы инициативаны түбәндәге сорауларны кертеп үткәрергә:

«Сез, 2020 елда Олы Подберезье авыл җирлегендә 18 яше тулып, референдумда катнашу хокукы булган һәр кешедән үзара салым акчасының бер тапкыр 500 (биш йөз) сум күләмендә түләнүе белән килешәсезме». Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлешләрдә тотыла:

*а)* җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- материаллар сатып алып, күперләрне ремонтлау;

*б)* җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

- җирлек торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын тоту;

в) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

-материаллар сатып алган зиратларны чистарту һәм ремонтлау.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://bpberez-kaybici.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" түбәндәге адрес буенча басытырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен Олы Подберезье авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Олы Подберезье авыл җирлеге башлыгы** **Ф.А.Чекмарев**